**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Яңа Сәет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**22 ноябрь 2023 ел** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2022 елның 25 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Яңа Сәет торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү**

1) гидрант урнаштыру

**2. Урам яктырту җайланмалары, ремонт:**

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү
2) материаллар, светодиод лампалар сатып алу

**3. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге:**

1) кышкы чорда юлларны карап тоту
2) җәйге чорда юлларны карап тоту
3) юлны ремонтлау, материаллар сатып алу
4) урамнарны грейдирлау
5) юл кырындагы үләнне чабу, кардан чистарту
6) юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру

**4.Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрн төзекләндерү:**

1) Бөек Ватан сугышы обелискын ремонтлау, территорияне төзекләндерү

**5. Яр буе зоналарын, сулыкларны төзекләндерү һәм чистарту:**

1) «Куркулда» инеш кушылдыгын төзекләндерү һәм чистарту

**6. Традицион күмү урыннарын карап тоту:**

1) каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) зират территориясендә үлән чабу
3) карт агачларны кисү
4) койма-киртәләрне ремонтлау

**7. Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**

1) су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү
2) су системасында агымдагы ремонт эшләре

**8. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:**

1) массакүләм чаралар урынын төзекләндерү
2) халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу

Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 138 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 85, бу 62% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 68 кеше «РИЗА» позициясе өчен,
17 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Яңа Сәет торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Сораулар буенча карар кабул итәргә:
"2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Яңа Сәет торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**1.Беренче янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү**

1) гидрант урнаштыру

**2. Урам яктырту җайланмалары, ремонт:**

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү
2) материаллар, светодиод лампалар сатып алу

**3. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге:**

1) кышкы чорда юлларны карап тоту
2) җәйге чорда юлларны карап тоту
3) юлны ремонтлау, материаллар сатып алу
4) урамнарны грейдирлау
5) юл кырындагы үләнне чабу, кардан чистарту
6) юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру

**4. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:**

1) Бөек Ватан сугышы обелискын ремонтлау, территорияне төзекләндерү

**5. Яр буе зоналарын, сулыкларны төзекләндерү һәм чистарту:**

1) «Куркулда» инеш кушылдыгын төзекләндерү һәм чистарту

**6. Традицион күмү урыннарын карап тоту:**

1) каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) зират территориясендә үлән чабу
3) карт агачларны кисү
4) койма-киртәләрне ремонтлау

**7. Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**

1) су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү
2) су системасында агымдагы ремонт эшләре

**8. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:**

1) массакүләм чаралар урынын төзекләндерү
2) халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу”- **кабул ителгән**

3. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе Исәнсеф
авыл җирлеге башлыгы Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының И.А.Салихов